Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл Советы

КАРАРЫ

12 декабрь 2024 ел № 102

Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл Советының 2018 елның “24” августындагы 41 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы «Татарстан Республикасында депутатларның, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларның, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә

Яңа Кәшер авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл Советының 2018 елның “24” августындагы 41 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл Советының 2020 елның 11 декабрендәге 6 номерлы, 2022 елның 27 октябрендәге 51 номерлы, 2022 елның 14 декабрендәге 56, 2024 елның июнендәге 94 номерлы, карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарга 1 нче кушымтадагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Вазыйфаи оклад (11 группа хезмәткә түләү) |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 20 985 |

| | |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесенең урынбасары | 20 566» |

1.2. карарга 2 нче кушымтадагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлаулы вазыйфаи затларының ай саен акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Ай саен акчалата бүләкләү күләме (11 группа хезмәткә түләү) |
|---|---|
| Башлык | 20 991 |
| Башлык урынбасары | 15 085» |

2. Әлеге карарны Яңа Кәшер авылы, Тавабилов урамы, 153 йорт, Бикасаз авылы, Мәктәп урамы, 1а йорт, территориясендә урнашкан махсус стендларда халыкка игълан итәргә, шулай ук Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 январеннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Яңа Кәшер авыл
җирлеге башлыгы — Л.М. Гыйниятуллина